# ЗАКОН
# РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О статусе депутата Государственного Совета Республики Татарстан» и Закон Республики Татарстан «О государственных должностях Республики Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
20 апреля 2023 года

**Статья 1**

Внести в главу I Закона Республики Татарстан от 18 марта 2004 года № 15-ЗРТ «О статусе депутата Государственного Совета Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 3 (I часть); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I часть); 2011, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I часть), № 12 (II часть); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 52 (часть I), № 94 (часть I); 2020, № 57 (часть I); 2021, № 1 (часть I), № 57 (часть I); 2023, № 3 (часть I), № 20 (часть I), № 27 (часть I) изменение, дополнив ее статьей $10^6$ следующего содержания:

«Статья $10^6$. **Порядок уведомления депутатами о фактах обращения к ним каких-либо лиц в целях склонения их к совершению коррупционных правонарушений**

1. Уведомление о факте обращения в целях склонения к совершению коррупционного правонарушения (далее – уведомление) составляется в письменном виде в произвольной форме.

2. В уведомлении указываются следующие сведения:

а) фамилия, имя и отчество (при наличии) депутата, подавшего уведомление;

б) место жительства, контактный телефон депутата, подавшего уведомление;

в) информация о дате, времени, месте и обстоятельствах обращения к депутату в целях склонения его к совершению коррупционного правонарушения;

г) способ склонения депутата к совершению коррупционного правонарушения (подкуп, угроза, обещание, обман, насилие и иные способы);

д) подробное описание деяния (действия или бездействия), содержащего признаки коррупционного правонарушения, к совершению которого склонялся депутат;

е) все известные сведения о лице (лицах), склонявшем (склонявших) депутата к совершению коррупционного правонарушения;

ж) дата подписания уведомления;

з) подпись депутата, подавшего уведомление.

3. К уведомлению прилагаются все имеющиеся материалы, подтверждающие обстоятельства обращения каких-либо лиц в целях склонения депутата к совершению коррупционного правонарушения.».

**Статья 2**

Внести в Закон Республики Татарстан от 4 марта 2006 года № 16-ЗРТ «О государственных должностях Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2006, № 3 (I часть); 2007, № 7 (I часть); 2008, № 7 (II часть), № 12 (I часть); 2009, № 12 (II часть); 2010, № 1 – 2, № 4 (I часть); 2011, № 5; 2012, № 7 (I часть); 2013, № 2 (I часть), № 3, № 11 (I часть); 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть); 2015, № 11 (I часть); 2016, № 4, № 6 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 52 (часть I); 2018, № 1 (часть I); 2020, № 37 (часть I), № 87 (часть I); 2021, № 57 (часть I); 2022, № 83 (часть I) изменение, дополнив его статьей $9^2$ следующего содержания:

«Статья $9^2$. **Порядок уведомления лицами, замещающими государственные должности Республики Татарстан, о фактах обращения к ним каких-либо лиц в целях склонения их к совершению коррупционных правонарушений**

1. Лица, замещающие государственные должности Республики Татарстан (за исключением депутатов Государственного Совета Республики Татарстан), обязаны уведомлять органы прокуратуры или Администрацию Главы (Раиса) Республики Татарстан обо всех фактах обращения к ним каких-либо лиц в целях склонения их к совершению коррупционных правонарушений в срок не позднее пяти дней со дня соответствующего обращения.

2. Уведомление о факте обращения в целях склонения к совершению коррупционного правонарушения (далее – уведомление) составляется в письменном виде в произвольной форме.

3. В уведомлении указываются следующие сведения:

1) фамилия, имя и отчество (при наличии) лица, замещающего государственную должность Республики Татарстан, подавшего уведомление;

2) полное наименование замещаемой государственной должности Республики Татарстан лица, подавшего уведомление, место жительства, контактный телефон;

3) информация о дате, времени, месте и обстоятельствах обращения к лицу, замещающему государственную должность Республики Татарстан, в целях склонения его к совершению коррупционного правонарушения;

4) способ склонения лица, замещающего государственную должность Республики Татарстан, к совершению коррупционного правонарушения (подкуп, угроза, обещание, обман, насилие и иные способы);

5) подробное описание деяния (действия или бездействия), содержащего признаки коррупционного правонарушения, к совершению которого склонялось лицо, замещающее государственную должность Республики Татарстан;

6) все известные сведения о лице (лицах), склонявшем (склонявших) лицо, замещающее государственную должность Республики Татарстан, к совершению коррупционного правонарушения;

7) дата подписания уведомления;

8) подпись лица, замещающего государственную должность Республики Татарстан, подавшего уведомление.

4. К уведомлению прилагаются все имеющиеся материалы, подтверждающие обстоятельства обращения каких-либо лиц в целях склонения лица, замещающего государственную должность Республики Татарстан, к совершению коррупционного правонарушения.».

**Статья 3**

Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
03 мая 2023 года
№ 39-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 20 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 бүлегенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 27 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле $10^6$ статья өстәп, үзгәреш кертергә:

«$10^6$ статья. **Депутатларның аларны коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында үзләренә нинди дә булса затларның мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр итү тәртибе**

1. Коррупциячел хокук бозу кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) ирекле формада язмача әзерләнә.

2. Хәбәрнамәдә түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

а) хәбәрнамә тапшырган депутатның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта);

б) хәбәрнамә тапшырган депутатның яшәү урыны, телефоны;

в) депутатка аны коррупциячел хокук бозу кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү датасы, вакыты, урыны һәм рәвеше турында мәгълүмат;

г) депутатны коррупциячел хокук бозу кылуга тарту алымы (акча тәкъдим итү, янау, вәгъдә бирү, алдалау, көч куллану һәм башка алымнар);

д) депутат җәлеп ителгән коррупциячел хокук бозу билгеләре булган гамәлләрне (гамәл кылуны яисә гамәл кылмауны) җентекләп тасвирлау;

е) депутатны коррупциячел хокук бозу кылуга тарткан зат (затлар) турында барлык билгеле белешмәләр;

ж) хәбәрнамәгә имза кую датасы;

з) хәбәрнамә тапшырган депутатның имзасы.

3. Хәбәрнамәгә депутатны коррупциячел хокук бозу кылуга тарту максатларында аңа нинди дә булса затларның мөрәҗәгать итү рәвешен раслый торган барлык булган материаллар өстәп тапшырыла.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле $9^2$ статья өстәп, үзгәреш кертергә:

«$9^2$ статья. **Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның аларны коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында үзләренә нинди дә булса затларның мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр итү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затлар (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларыннан тыш) аларны коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында үзләренә нинди дә булса затларның мөрәҗәгать итүе турындагы барлык фактлар хакында шундый мөрәҗәгать булган көннән алып биш көн эчендә прокуратура органнарына яисә Татарстан Республикасы Рәисе администрациясенә хәбәр итәргә тиеш.

2. Коррупциячел хокук бозу кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү факты турында хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) ирекле формада язмача әзерләнә.

3. Хәбәрнамәдә түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) хәбәрнамә тапшырган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта);

2) хәбәрнамә тапшырган зат били торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасының тулы исеме, әлеге затның яшәү урыны, телефоны;

3) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затка аны коррупциячел хокук бозу кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү датасы, вакыты, урыны һәм рәвеше турында мәгълүмат;

4) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затны коррупциячел хокук бозу кылуга тарту алымы (акча тәкъдим итү, янау, вәгъдә бирү, алдалау, көч куллану һәм башка алымнар);

5) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат җәлеп ителгән коррупциячел хокук бозулар билгеләре булган гамәлләрне (гамәл кылуны яисә гамәл кылмауны) җентекләп тасвирлау;

6) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затны коррупциячел хокук бозу кылуга тарткан зат (затлар) турында билгеле булган барлык белешмәләр;

7) хәбәрнамәгә имза кую датасы;

8) хәбәрнамә тапшырган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның имзасы.

4. Хәбәрнамәгә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затны коррупциячел хокук бозу кылуга тарту максатларында аңа нинди дә булса затларның мөрәҗәгать итү рәвешен раслый торган барлык булган материаллар өстәп тапшырыла.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 03 май
№ 39-ТРЗ